ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

12.12.2022 Баулы шәһәре № 260

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Баулы муниципаль районы башкарма комитетының структур бүлекчәләре (бүлекләре) булып торучы муниципаль казна учреждениеләре җитәкчеләренә, белгечләренә хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 19 апрелендәге 104 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2023 елның 1 гыйнварыннан башкарма комитетларның структур бүлекчәләре булган муниципаль казна учреждениеләренең җитәкчеләренә, үзәкләштерелгән бухгалтерия белгечләренә һәм бухгалтерлык исәбе бүлекләренә хезмәт өчен түләүнең яңа системасын кертү турында 2022 елның 9 августындагы 03-16/5605 номерлы хаты нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Баулы муниципаль районы башкарма комитетының структур бүлекчәләре (бүлекләре) булып торучы муниципаль казна учреждениеләре җитәкчеләренә, белгечләренә хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 19 апрелендәге 104 номерлы карарына (Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 4 сентябрендәге 178 номерлы, 2020 елның 2 октябрендәге 191 номерлы, 2022 елның 26 октябрендәге 221 номерлы карарлары кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Җирле үзидарә органнарының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль казна учреждениесе, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Мәгариф бүлегенең үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль казна учреждениесе, «Татарстан

Республикасы Баулы муниципаль районының мәдәният бүлеге» муниципаль казна учреждениесе бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге, «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының спорт һәм туризмны үстерү бүлеге» муниципаль казна учреждениесенең бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылыгы бүлеге, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Яшьләр эшләре буенча бүлеге» муниципаль казна учреждениесенең бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге» муниципаль казна учреждениесе җитәкчеләренә һәм белгечләренә түләүне оештыру һәм шартлары турындагы нигезләмәдә 3 пунктның түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

| Җитәкче һәм белгеч вазифасы | Вазифаи оклад, сум | |
|---|---|---|
| | Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен | Башкарма комитетның (җирле үзидарәнең башка органының) структур бүлекчәләре (бүлекләре) булып торучы муниципаль казна учреждениеләренең үзәкләштерелгән бухгалтериясе, бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлекләре өчен |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 27 700 | |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 25 500 | |
| Башкарма комитетның структур бүлекчәсе җитәкчесе (баш бухгалтер) | | 25 500 |
| Бүлек җитәкчесе | 21 700 | 21 700 |
| Әйдәүче бухгалтер | 19 300 | 19 300 |
| Бухгалтер | 18 000 | 18 000 ». |

2. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров